**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Гулкин авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**31.01.2022 ел**

**№54**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 14 гыйнварыннан 127 номерлы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 202_ елның 14 гыйнварыннан 127 номерлы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның 29 абзацында «, 50 кв. м дан артык мәйданда һәм 30 куб. м дан артыграк күләмдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 40 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40. Индивидуаль торак йортлар милекчеләре (яки) яллаучылар (алга таба - торак йортлар хуҗалары), әгәр закон яки килешү белән башкасы каралмаган булса, бурычлы:

1) торак йортларның фасадларының, коймаларның (киртәләрнең), шулай ук йорт биләмәләре чикләрендә башка корылмаларның тиешле торышын тәэмин итәргә, аларны үзвакытында ремонтлау һәм буяуны башкарырга;

2) торак йортта номер билгесен тиешенчә урнаштырырга һәм аны төзек хәлдә тотарга;

3) йорт биләмәсе территориясен тәртиптә тотуны һәм тиешле санитар халәттә тотуны тәэмин итү;

4) газүткәргечләрнең, кабельле һәм һава электр үткәргечләренең һәм башка инженерлык челтәрләренең сак зонасында агачлар утыртырга рөхсәт

итмәскә;

5) якын-тирәдәге территориядән чистартылган карны транспорт юлына, аларда инженерлык коммуникацияләренә һәм корылмаларга керүгә, җәяүлеләрнең үтеп йөрүенә комачауламаслык итеп һәм яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итәрлек итеп өяргә;

6) үзәкләштерелгән канализация булмаганда бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә санитар нормалар нигезендә җирле канализация, юынтык сулар чокыры, бәдрәф ясарга, аларны даими рәвештә чистартып һәм дезинфекцияләп тотарга;

7) каты коммуналь калдыкларны пакетларга яисә каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарында (мәйданчыкларында) региональ оператор тарафыннан бирелгән башка савытларга салырга.»;

1.3. 83 пунктның икенче абзацында «23.00 сәгатьтән 7.00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «22.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр - эш көннәрендә, ә ял көннәрендә һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә - 22.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр,» сүзләре белән алмаштырырга;

1.4. 125 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«125. Шәхси торак төзелеше территориясендә рөхсәт ителми:

1) йорт биләмәләре чикләреннән читтә койма кую;

2) йорт биләмәләре чикләрендә һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә яфраклар, теләсә нинди калдыклар һәм чүп-чар яндыру;

3) йорт яны территориясеннән читтә тирес, күмер, тара, утын, эре габаритлы калдыклар, төзелеш материаллары өеп кую;

4) "Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге җирләрендә йорт биләмәсе территориясеннән читтә транспорт чараларын юарга;

5) вәкаләтле органнар белән килештермичә, йорт биләмәсе территориясе артында корылмалары төзергә, чүп-чар чокырлары ясарга;

6) әлеге территориянең урамнарында махсус транспорттан һәм урып-җыю техникасыннан файдалану мөмкинлеген кыенлаштыра торган яисә аларга комачаулаулый торган капламалар урнаштырырга;

7) территорияне төзекләндерү элементларын җимерергә һәм бозарга, сулыкларны пычратырга;

8) "Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге җирләрендә йорт биләмәсе территориясеннән читтә сүтелгән (төзек булмаган) транспорт чарасын куярга һәм сакларга;

9) якын-тирәдәге территорияне теләсә нинди калдыклар белән чүпләргә;

10) чүплек, кар, боз өемнәре ясарга.»;

1.5. 124 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-каты коммуналь калдыклар өчен контейнерлар урнаштыруны;»;

1.6. 174 пунктта «7.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «эш көннәрендә 6.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр, ә ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә 9.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый

мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе С.Д.Инькова